**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы**
**Әхмәт авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

28.04.2021 ел № 15

**Җирле салымнар буенча недоимканы һәм пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип табуның өстәмә нигезләре турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Җирле салымнар буенча вакытында түләнми калган өлеше, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә (алга таба - бурыч) өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә (алга таба-бурыч):

бурыч барлыкка килү срогы өч елдан артып киткән очракта, җир салымы һәм вафат булган физик затлар милкенә салым буенча;

җир салымы һәм вафат булган физик затлар мөлкәтенә салым буенча, мирас хокукы гамәлгә кергән көннән алып 6 ай эчендә мираска гариза бирелмәгән очракта;

җирле салымнар буенча суд приставы-башкаручы тарафыннан “Башкару эшчәнлеге турында” 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында билгеләнгән нигезләрдә башкарма документны алучысына кире кайтару турында карар чыгарылган очракта.

2. Салым түләүченең бурычы исемлеге салым органы тарафыннан әлеге карар һәм салым органының вакытында түләнми калган өлеш һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч суммалары турындагы белешмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга һәм җирлек территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әхмәт авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Х.Шәйхетдинов